**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 26 июнь № 437

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыруга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2016 ел, 28 июль, 519 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт ярдәме акчасы исәбеннән финанслана ала торган күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыруга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2016 ел, 28 июль, 519 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт ярдәме акчасы исәбеннән финанслана ала торган күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта «су бүлү» сүзләреннән соң «, индивидуаль җылылык пунктлары (ИҖП) һәм, булган очракта, күтәрткеч насос җайланмалары урнаштыру, ремонтлау яки җиһазлар комплексында алмаштыру» сүзләрен өстәргә;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Күпфатирлы йортның нигезен, шулай ук тотып торучы диварларны, түшәмә, балкон плитәләрен һәм башка плитәләрне, тотып торучы колонналарны һәм башка киртәләүче тотып торучы конструкцияләрне ремонтлау һәм (яки) ныгыту.»;

8 пунктка «, аерым милекчеләрнеке булмаган һәм бүлмәләр милекчеләренең социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен каралган күпфатирлы йорттагы башка урыннар» сүзләрен өстәргә;

11 нче пунктка «, шулай ук капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\437.docx